| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>КУКМОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР<br>422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15 | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ<br>422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15 |

РЕШЕНИЕ КАРАР

16 март 2021 ел №6

Кукмара муниципаль районы Советының 2017 елның 29 сентябрендәге 21 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1. Кукмара муниципаль районы Советының 2017 елның 29 сентябрендәге 21 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (2018 елның 04 маендагы 7 номерлы, 2018 елның 23 ноябрендәге 24 номерлы, 2019 елның 24 маендагы 10 номерлы үзгәрешләр редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 бүлекнең 20 пунктында «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

2) 12 бүлекнең 1.3 пунктындагы 4 пунктчасында «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр» сүзләрен өстәргә;

3) 20 бүлекнең 9 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр һәм (яисә) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе, шулай ук кирәк булганда муниципаль хезмәт стажын раслый торган һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 30 статьясында күрсәтелгән башка документларның күчермәләре;»

4) 20 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 16.1 пункт өстәргә:

«16.1. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән затның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмаганда башкарыла.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү турында мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көн эчендә җайга салынганда тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү мондый билгеләнеш өчен мөрәҗәгать иткән көннән алып башкарыла.»

5) 25 бүлекнең 1 пунктындагы 4 пунктчасында «(булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр булдыру һәм һәм күрсәтелгән белешмәләрне Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшыру» сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Кукмара шәһәре Мэры С.Д. Димитриев